Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№14 (144)

13 ноябрь 2015 ел


Фән көннәре – 2015

Редакция архивы фотосы

Ел саен 10 ноябрьдә фән көне билгеләп үтелә. Ул ЮНЕСКО тарафыннан 2001 елда кабул ителгән. Төп максат – фән белән җәмгыять арасында тыгызрак элемтә булдыру. Шуны истә тотып, барлык илләрдә дә фәнгә бәйле чаралар уздырыла. КФУда исә «Фән көннәре – 2015» фестивале тулы бер декаданы үз эченә алды. Ачык лекция, университет музейларына һәм лабораторияләренә экскурсияләр – боларның барысы фестиваль кысаларында 1 нче ноябрьдән үк оештырыла килде. 10 ноябрьдә узган «Фәнни көрәш клубы»ның ачылыш тантанасы фестивальнең иң югары ноктасы булды.

## Вакыйгалар эзеннән

### ОЧРАШУ

Фестиваль мәктәп укучыларына КФУның фәнни дөньясы турында күбрәк белү мөмкинлеге тудырды. Абитуриентлар белән очрашулар университетның барлык бүлекләрендә диярлек уздырылды. Мисал өчен, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институтының конфликтология кафедрасы «Конфликтология – мәктәп укучысына ярдәмгә: XXI гасырда конфликтология ни өчен кирәк?» дип аталган интерактив дәрес тәкъдим итте. Чара эшлекле уен элементлары һәм мультипликацияле видеосюжетлар карау белән үрелеп барды.





### ЭКСКУРСИЯ

Һәр фәннең тарихы бар. Аны китаптан укып белү генә җитми, күрергә дә кирәк. Мондый мөмкинлекне музейлар бирә. «Фән көннәре – 2015» фестивале вакытында КФУ музейларыннан кеше бер дә өзелмәде. Э.А.Эверсман исемендәге Зоология музее, А.А.Штукенберг исемендәге Геология музее, Казан химия мәктәбе музее һәр теләгән кеше өчен кызыклы экскурсияләр үткәрде. Казан химия мәктәбе музее директоры Гөлнара Вәлитова сүзләренә караганда, фестиваль дәверендә музейда 100дән артык кеше булып чыккан. Химия белән кызыксынучылар Татарстаннан гына түгел икән, кунаклар арасында Новосибирск, Чабаксар һәм Башкортстаннан килүчеләр дә булган.

### ФӘННИ КӨРӘШ КЛУБЫ

Фәнни көрәш (фәнни слэм) ул – галимнәрнең stand-up форматында ярышы. Әлеге чара КФУның Яшь галимнәр ассоциациясе тарафыннан оештырылды. Фәнни көрәштә галимнәр үз тикшеренүләре турында 10 минут эчендә аңлаешлы һәм кызыклы итеп сөйләргә тиеш. Иң яхшы чыгышларны тамашачылар тавыш бирү аша билгелиләр. Фәнни көрәш – яңа һәм бик мавыктыргыч чара, ул фәнне яшьләр арасында популярлаштыра. Мондый төр бәйгеләр Германия, Франция, Россиянең алдынгы университетларында бик тиз таралган. Хәзер исә фәнни көрәш КФУда да һәрдаим узачак. Ачылыш тантанасында эмоциональ машиналар, кара энергия, киләчәк машинасы өчен супер аккумулятор, интуиция турында чыгышлар ясалды. Кызык: киләсе чаралар нинди фәнни ачышлар белән истә калыр икән?



• Фән дөньясында

# Айзирәк Садыйков – яшь энтомолог

Зирәклек, тырышлык кебек сыйфатлар хас бу егеткә. Уку алдынгысы, төркемнәрендә староста, фән белән кызыксынучы, булачак биология һәм химия укытучысы.

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты



Аның өчен гади бер бөҗәк кыйммәтле табылдыкка, фәнни ачыш предметына әверелергә мөмкин. Сүзем КФУ Фундаменталь медицина һәм биология институтының 3 нче курсында укучы **Айзирәк Садыйков** турында. Бүген ул ныклап торып биологиянең бер тармагы – бөҗәкләр турындагы фән – энтомология белән шөгыльләнә.

Ул тумышы белән Чистай районының Мөслим авылыннан. Урта мәктәпне тәмамлагач, укытучы булу теләге аны КФУга алып килә. Юкка түгел, әлбәттә. Мәктәптә укыганда, биология укытучысы Ленар абыйсы Хәбибуллин дәресләрен көтеп ала торган була ул. Укытучы үз укучысында бүген югалып барган сыйфат – табигатькә мәхәббәт тәрбияләгән. Айзирәк үзе дә, әгәр укытучы булмасам, һичшиксез, урманчы булыр идем, дигән фикердә тора.

– Ә энтомология белән кызыксыну беренче курста укыганда башланды, – дип сөйләп китте Айзирәк. – Беренче курс тәмамланганнан соң, умырткасыз хайваннар темасы буенча Займищеда җәйге практика үттек. Җитәкчебез – укытучы **Порфирьев Андрей Георгиевич** миндә нәкъ шушы темага кызыксыну уятты. Коллекциямә беренче бөҗәкләр шунда җыелды.



Айзирәк бүген бөҗәкләр коллекциясе җыю белән мәшгуль. Беренче курстан бирле 210га якын экземпляр җыелган, 30 төр ачыкланган. Быел Ак диңгезнең Средний утравында узган җәйге практикасыннан гына да 160 экземпляр алып кайта ул. Җыйдың да эш бетте түгел әле. Иң беренчесе – кыр көндәлегенә аларның кайда, кайчан, нинди шартларда (һава торышы, җил, кояш) тотылганын сурәтләп теркәргә кирәк. Махсус савытта (ә ул егетнең һәрчак үзе белән!) йоклатылган бөҗәкне җебетәсе, киптерәсе һәм үзең ясаган тартмага урнаштырасы бар. Кыскасы, бу айларга сузыла торган процесс. Иң кызыгы – махсус төрбилгеләгеч сүзлек белән эшләү – бөҗәкнең нинди төргә керүен, нәрсә булуын билгеләү. Коллекцияләр җыюының төп максаты – киләчәктә педагогик юнәлештә эшли калсам дип, укучыларга күрсәтмә материал туплау икән.

– Җыелганнар арасында иң күбе – коңгызлар. Иң кызыклысы һәм зурысы – мәче тотып биргән мөгезборын кондыз булгандыр, мөгаен.

Беренче фәнни адымнарын Айзирәк туган ягыннан, авыл тирәләрен, урман-кырларны тикшерү, өйрәнүдән башлый. Коллекциясенә беренче экземплярлар да шуннан туплана.

– Ел саен 4000 бөҗәк ачылып тора. Бөҗәкләргә кагылышлы фәнни эшләр язылып беткән, дип әйтү дөрес түгел. Бүген теркәлгән бөҗәкләр саны миллионнан артык булса да, алар әле өйрәнелмәгән дип әйтү дөрес булыр. Алар тормышындагы чорларны, экологиясен, генетикасын берничә фән киселешендә өйрәнергә мөмкин.

Әйткән фикерләре төпле, үзе зирәк Айзирәк. Мәктәпкә мондый укытучылар бик кирәк!

• Белем бураэналары

# Татар телендә онлайн университет булачак

**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА**

«Татар телендә фән бармы? Аның үткәне нинди? Бүген ничек яши ул? Ә киләчәге ничек булыр дип көтелә?» Әлеге сораулар берәүне дә битараф калдырмыйдыр, мөгаен. Көн кадагында торган мәсьәләләргә җавап табу максатыннан, фәнни дөнья белән безне тоташтыручы күперләр – галимнәр, университет мөгаллимнәре татар телендәге фән хакында фикер алышты.

Ни дисәң дә, фән – җәмгыятьне алга этәрүче иң зур, куәтле көчләрнең берсе. Гадәттә, фән дигәч, чал чәчле, күзлек кигән ханым-әфәнделәр күз алдына килә. Килә иде! Хәзер заман башка төрле кагыйдәләр тәкъдим итә. Кызыклы булмаска тиеш кебек тоелган күп нәрсәләр хәзер, киресенчә, яшьләрдә мавыгу уята. Фән-фәһем – шундыйлардан.

Фәнне татарча аңлаешлы телдә зур җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү – КФУның Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты студенты Айдар Шәйхи идеясе. Әлеге идея «Гыйлем» дип аталган интернет-проект буларак тормышка аша. Ул җәмгыять, табигать, медицина, төгәл фәннәр, тел һәм лингвистика өлкәләрен яктыртып бара. Статистика буенча проект кысаларында инде 85 мәкалә язылган, 12 инфографика әзерләнгән, 5 анимацион дәрес тәрҗемә ителгән. Проект авторы сүзләренә караганда, сайтка, татар телендә фәнни мәгълүмат эзләп, 21 илдән керәләр.

Ныклы адымнар белән үсә барган «Гыйлем» берләшмәсе, галим-голамәләрне бергә җыеп, татар фәненең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында фикер алышты. Бу чара Бөтендөнья татар яшьләре форумы белән берлектә уздырылды. «Татар телендәге фәннең үсешенә киртәләр нинди?» дигән түгәрәк өстәл КФУ доценты, физика-математика фәннәре кандидаты Әнис Галимҗанов, КМТТУ-КАИ профессоры, физика-математика фәннәре кандидаты Гамир Мөбәрәкҗанов, КДАТУ механика кафедрасы профессоры, физика-математика фәннәре кандидаты Рәшит Шакирҗанов, Татар энциклопедиясе институты директоры, КФУның татарларны өйрәнү һәм тюркология кафедрасы мөдире, тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев, Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының директор урынбасары Олег Хисамов кебек шәхесләрне үзенә җыйды.

Бөтендөнья татар яшьләре форумының рәисе урынбасары, түгәрәк өстәлнең модераторы Рашат Якупов бу чараның кирәклеген ассызыклады: «Татар фәнен интернет киңлегенә чыгарырга теләүчеләр бихисап икән. Моңа кадәр энтузиастларны бергә туплау кыен булса, хәзер инде «Гыйлем» проекты кысаларында бу – реаль әйбер. Проектка татар галим-голамәләренең фәнни-методик киңәше, материаллары кирәк иде. Югары уку йортларында татар теле һәм әдәбиятын гына түгел, математика, физика, химия, биология кебек табигый фәннәрне, тарихны да татарча укыткан галимнәр, «Гыйлем» проекты белән кызыксынып, үзләренең фәнни-методик хезмәтләре белән уртаклашырга теләк белдерде инде».

Энтузиазм дигәннән, Искәндәр Гыйләҗев Татар энциклопедиясе институтында «Онлайн татар энциклопедиясе»н ачу хыялы белән яна икән. Тик бу проектка энтузиастлар ярдәме кирәк, диде галим. «Дәүләткә генә өметләнеп булмый. Иң зур өмет – энтузиастларда, халыкның идеализмында. Без халыкта идеализмны тәрбияли алсак, әле өмет бар дип саныйм. Мин үзем өчен җавап бирәм, минем балаларым, оныкларым татарча сөйләшәчәк, дип әйтә алган кешеләр күп булса, киләчәктә өмет бар», – дип белдерде Искәндәр Гыйләҗев.

«Гыйлем» проектының планнары зурдан. «Без әлегә яңа форматта популяр фәнни контент булдырабыз, алга таба видеодәресләр, татар галимнәренең лекцияләре яздырылачак, фәнни эзләнүләр яктыртылачак. Һәм киләчәктә онлайн лицей һәм онлайн университет төзеләчәк», – ди Айдар Шәйхи.

Моңа өстәп, Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе Тәбрис Яруллин мисалга, Чехия тәҗрибәсен китерде: «Чех телендә интернет аша югары белем алып була, һәм ул бушка. Дәүләт, шулай итеп, чех телен саклый һәм үстерә. Без татар милләтен, татар телен сакларга телибез икән, бу җыр-биюләргә генә кайтып калмасын, интеллектуаль юнәлештә дә үсеш булсын иде. Татарлар Милли университет ачу турында күпме хыялланды, хәзер аны интернетта оештырып була, һәм моңа беркем комачаулый алмый».

• • • •

Очрашудан соң «Татар фәненең киләчәге бармы?» дигән сорауга тулы ышаныч белән «Әйе!» дип җавап бирергә була. Фән хәзер яшь, заманча һәм, иң мөһиме, татарча икән!

• Белми калма!

2015 елның 20 ноябрендә КФУда «Татар журналистикасының төрки телле мәгълүмати киңлектәге урыны һәм роле» дип исемләнгән Россиякүләм фәнни-гамәли конференция үз эшен башлап җибәрәчәк.

# Бөек иҗатчы мирасына багышлана



Әлеге чара күренекле әдип, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе **Гаяз Исхакый** истәлегенә багышлана.

Конференция «Татмедиа» акционерлар җәмгыяте белән Казан (Идел буе) федераль университетының Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты тарафыннан оештырыла. Конференциянең мәгълүмати партнерлары – «Безнең мирас»журналы һәм «Intertat.ru» электрон газетасы.

Конференциядә түбәндәге секцияләр эшләр дип планлаштырыла:

- Татар басма матбугаты: хәзерге проблемалар, үсеш перспективасы.
- Татар журналистикасы тарихын өйрәнү проблемалары.

Конференциядә читтән торып та, килеп тә катнашып була. Фәнни-гамәли конференциягә татар һәм рус телләрендә язылган эшләр җибәрелергә мөмкин. Кабул ителгән мәкаләләр җыентыкка тупланачак. Җыентыкның электрон төре конференциядән соң КФУның рәсми сайтында дөнья күрәчәк.

Тезисларны һәм катнашу өчен гаризаларны, 2015 елның 15 ноябреннән дә соңармыйча, ***tat.konf@mail.ru*** электрон почтасына юлларга кирәк.

**• Телләр белгән, илләр гизгән**

XVIII гасырда Россиядә үзен хөрмәт иткән һәр кеше француз телендә иркен сөйләшергә, инглизчәне су кебек эчәргә тиеш дип саналган. Тора-бара әлеге таләп юкка чыкса да, хәзерге заманда полиглотлар бар һәм алар кирәк, алай гына да түгел, полиглотларга яшәү дә рәхәтрәк кебек... Россиядә ошамый башласа, Төркиягә күченеп китәсең. Төркия ялкытса – Германиягә... Сәяхәтче бака кебек, төрле телдә такылдап тик йөрисең. Ләкин андый булыр өчен, телләр өйрәнү зарур. Ә моның өчен зур көч һәм вакыт кирәк. Телләрне үзләштерү җиңел булсын дисәң, үзеңә кызыклы һәм ошый торганыннан башларга тәкъдим ителәр. Бу очракта «зубрежка» да ялкытмаячак.

# «Сәяхәтче бака»

**Лиана МӘРДАНОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Полиглотлар белдерүенчә, үз теленең грамматикасын, лексикасын һәм башка өлкәләрен белмәгән кешегә телләрне үзләштерү авыргарак туры килә икән. Сыйфат белән фигыльнең нинди сорауларга җавап бирүен булса да өйрәнергә туры киләчәк...

Инглиз һәм башка телләрне тирәнрәк өйрәнү өчен, махсус курсларга йөрергә була. Казанда алар шактый күп. Барлык тел мәктәпләрендә дә консультация һәм тест үтү бушлай оештырыла. Шулай булгач, дустым, барып карап кайтуның бер зыяны да булмас. Психологлар фикеренчә, кешегә хәтта тирә-юньнең нинди булуы да тәэсир ясый ала икән. Әгәр дә мәктәпнең аудиториясе, коллективның мөнәсәбәте ошамаса, син анда укый алмаячаксың. Финанс ягы авыррак булса, үзлектән өйрәнергә була. Социаль челтәрләрдә вакыт әрәм итеп утырганчы, телләр өйрәнү өчен файдалы сайтлар киңәш итәм: шәхсән үзем «Лингуст»та шөгыльләнеп маташам. Миңа ошый. ***lingust.ru*** сайтында барлыгы 12 тел өйрәнеп була. Аның эшчәнлегенә инде өч ел. Бар уку-укыту материалы бушлай. Теория өлешен үткәннән соң, үзлегеңнән төрле текстлар укып, аудиоязмалар тыңлап күнекмәләр алырга була. ***busuu.com/ru*** һәм ***lingualeo.com/ru*** – боларда уку-укыту программасы уенга корылган. Төрле сурәтләр, мисаллар ярдәмендә сүзләрне ятлау, үз сүзлегеңне булдыру мөмкинлеге бар. Әлеге сайтларның төрле телефоннар өчен махсус кушымталары да әзерләнгән. Киръсә, автобуста, йоклар алдыннан сүзләрне кабатлап алырга була. ***adme.ru*** – бу сайтта да күпләр үзләре өчен кызыклы, шул ук вакытта кирәкле материаллар таба алачак.

Дөньяда иң күп кулланыла торган телләр:

- **Инглиз теле.** Җир шарында яшәүчеләрнең өчтән бер өлеше инглизчә аңлаша икән. Хәзерге көндә үзен хөрмәт иткән һәркем инглизчә «Хеллоу» дип булса да әйтә белергә тиеш.
- **Испан теле.** ООНда эшләүчеләрнең аңлашуы әлеге телдә бара. Испанчаны үзләштерү җиңел дип санала.
- **Кытай теле.** Белгечләр фикеренчә, берничә елдан соң кытайлылар булмаган җир калмаячак икән. Шуңа күрә әлеге телне белү зарур булырга мөмкин.
- **Рус теле**. Евразиянең 250 млн кешесе русча белә. Рус телендә бик күп фәнни һәм технологик материаллар язылган, шуңа өстәп, рус теле бөек әдипләр – Толстой, Достоевскийлар теле дә.
- **Гарәп телендә** 400 млн кеше аралаша. Коръән әлеге телдә язылган. Гарәп теле шулай ук ООНның төп телләренең берсе булып санала. Грамматика һәм язуын өйрәнү, билгеле, авыр. Моңа өстәмәгә гарәп телендә диалектлар бик күп.

✦ **Альберт Исмаил,** җырчы:

*Мин 6 тел беләм. 18 яшемдә өйрәнә башладым. Хәзер телләр тамагымны туйдыра, акча китерә. Тел өйрәнүнең ысуллары күп, билгеле, шәхсән үземнән берничә киңәш бирә алам:*

- *тәүге этапта аерым сүзләрне түгел, ә җөмләләр ятларга кирәк;*
- *аңламасагыз да, кино карарга, радио тыңларга кирәк;*
- *мөмкин кадәр телнең грамматикасын аңларга тырышыгыз;*
- *төрле ситуацияләрне модельләштереп, аңа кагылышлы бөтен сүзләрне кулланып ятласагыз да комачауламас;*
- *мөһим момент: баш миендә киеренкелек булмаска тиеш. Тел өйрәнүне уен итеп кабул итү зарур;*
- *һәр ятланган сүздән ләззәт алыгыз.*

✦ **Гөлназ Вәлиева**, шагыйрә (хәзерге вакытта Берлинда яшәп иҗат итә):

*Яхшы белгәннәрем – алты тел. Әмма һәрбер күп тел белүче, яхшы белгәннәреннән кала, тагын берничә телне аңлый. Телләрне 10 яшьтән (5 нче сыйныфтан) өйрәнә башладым. Әлбәттә, һәрбер яңа тел яңа дөнья ача дияргә була. 6 елдан артык Германиядә яшим, монда да немец теленнән кала башка телләрне белүем бик булышты, яхшы эш табарга, мәсәлән. Телләрне берьюлы берничә ысул белән өйрәнү яхшы, минемчә. Телне өйрәнә башлау чорында кинолар карауның бик мәгънәсе юк, бераз нигез булдырырга кирәк. Шулай ук бөтенләй дәреслексез генә грамматиканы яхшы итеп өйрәнеп булмас. Ә инде телне бераз өйрәнгәннән соң, китап уку да, кино карау да, кешеләр белән аралашу да бик файдалы.*


**КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ОБЪЯВЛЯЕТ**

***конкурс на замещение должностей профессорско-преподавательского состава:***

● **Институт вычислительной математики и информатики:**
*ассистент:*
– кафедры теоретической кибернетики – 1 (1);
*доцент:*
– кафедры прикладной математики – 1 (1);
– кафедры технологий программирования – 1 (1);
*профессор:*
– кафедры прикладной математики – 1 (1);

● **Институт математики и механики им.Н.И.Лобачевского:**
*ассистент:*
– кафедры геометрии – 2 (2);
– кафедры теории функций и приближений – 0,5 (1);
*доцент:*
– кафедры математического анализа – 0,5 (1);

● **Подготовительный факультет для иностранных учащихся:**
*ассистент:*
– кафедры гуманитарных наук – 2 (2);
– кафедры русского языка – 1 (1);
*старший преподаватель:*
– кафедры гуманитарных наук – 0,5 (1);

**ЗАЯВЛЕНИЯ** вместе с документами, подтверждающими квалификацию кандидата, принимаются в Управлении кадров КФУ (420008, г. Казань, ул.Кремлевская, 18 каб.132 главного здания).

***конкурс на замещение должностей научно-педагогических работников для выполнения работ в рамках Плана мероприятий по реализации Программы повышения конкурентоспособности («Дорожной карты»):***

● **Институт физики** (Международный центр магнитного резонанса):
– младший научный сотрудник – 0,2 (1);
– старший научный сотрудник – 0,1 (2);
– ведущий научный сотрудник – 0,1 (1);
– старший научный сотрудник – 0,01 (1);

**ЗАЯВЛЕНИЯ** вместе с документами, подтверждающими квалификацию кандидата, принимаются в Управлении кадров ППК КФУ (420008, г. Казань, ул. Кремлевская, 18 каб.103 западный полуциркуль).

Информация о конкурсе, о сроках и месте проведения конкурса размещается на сайте Управления кадров официального портала КФУ ***kpfu.ru***.


**• Яшьлек – яңарыш**

# Яшьләр өчен «Во:время»

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

КФУда «Во:время» яшьләр аудио-видеоэшләр ачык халыкара фестивале үтте.



Фестиваль журналистика белән кызыксынучыларга да, аннан ерак булганнарга да, катнашып, үз көчеңне сынарга, билгеле бер күнекмәләр алырга мөмкинлек бирде. Аны оештыручылар арасында КФУның Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация, Филология һәм мәдәниятара багланышлар, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү, Яр Чаллы институтлары, Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе бар иде. Оештыручыларның шулай күп булуы һәм төрле өлкәләрне берләштерүе фестивальнең масштабы, аның барышында күтәрелгән темалар, оештырылган түгәрәк өстәлләр, осталык дәресләре, фәнни-гамәли конференция күп нәрсә хакында сөйли.

Конференциянең географиясе, быел беренче тапкыр гына үткәрелүгә карамастан, шактый киң. Үз эшләрен тәкъдим итүчеләр арасында Россиянең төрле төбәкләре генә түгел, Германия, Белоруссия һәм Украина да бар иде. Әмма иң сөенечлесе – аудиоэшләр буенча гран-приның бездә, КФУның Яр Чаллы институтында калуы. Биредә берничә ел «УРа» радиосы эшләп килә. Тырышып эшләгәч, нәтиҗәсе дә озак көттермәде.

Беренче карлыгачның киләчәге өметле. Чөнки ул студентларга үзләрен яңа яктан ачарга мөмкинлек бирә.

**• Туган тел сагында**

# «Tatarica» журналы EBSCO Publishing Database мәгълүматлар базасына кертелгән

2013 нче елда Казан университетында чыга башлаган «Tatarica» журналы заман таләпләренә тулысынча җавап бирә. Ул чит ил һәм үз галимнәребезнең тел, әдәбият, тарих, фольклор, фәлсәфә, дин, белем бирү, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге эшчәнлекләрен чагылдырып бара.



«*Без «Tatarica» журналын халыкара индекслана торган басмалар исемлегенә кертү буенча актив эш алып барабыз. Бу татар фәненең дәрәҗәсен арттыру, татар галимнәре эшчәнлеген халыкара мәйданга чыгаруда зур роль уйный*», – дип белдерде Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директорының фән эшләре буенча урынбасары **Искәндәр Ярмәкәев**.

Тырышлыкның нәтиҗәсе бар: 2015 нче елда Казан федераль университеты һәм EBSCO Publishing, Inc компаниясе арасында килешүгә кул куелган һәм «Tatarica» журналы EBSCO Publishing Database мәгълүматлар базасына кертелгән.

Искәндәр Ярмәкәев белдерүенчә, EBSCO Publishing Database базасына Blackwell Publishers, Springer, Elsevier, Harvard Business School, Taylor and Francis, Transaction Publishers, American Institute of Physics, University of California Press кебек танылган басмалар гына кертелгән икән. Әлеге ресурс иң зур коллекцияләрнең берсен тәшкил итә. Биредә 1950 нче елдан бирле чыгып килгән газета, журнал, китап, мультимедиа чаралары тупланган 350дән артык тулы текстлы база бар.

«*EBSCO мәгълүмат базасы АКШның академик китапханәләре сораштыруы буенча иң яхшысы дип табылган. Күп дисциплиналы базалар белән беррәттән, компьютер технологиясе, белем бирү кебек аерым фәннәрне дә туплый алуы ресурсның үзенчәлекле һәм кабатланмас булуын дәлилли*», – дип өстәде Искәндер Ярмәкәев.

Журнал редакциясе Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында урнашкан. Баш мөхәррире – Институт директоры **Рәдиф Җамалетдинов**. Журналның Халыкара редакцион берләшмәсен Синьцзян университеты профессоры **Аббас Абдулла** (Кытай), Ю.Либих исемендәге Гиссен университеты профессоры **Марк Кирхнер**, Вискон университеты профессоры **Юлай Шамильоглу**, Гарвард университеты профессоры **Шамил Сюняев**, Макс Планка исемендәге җәмгыятьнең Астрофизика институты директоры **Рәшид Сюняев** (Германия) кебек хөрмәтле һәм танылган кешеләр тәшкил итә.

Журнал татар, рус, инглиз телләрендә бастырыла, Россия һәм чит илләрдә яшәүче татар диаспораларына, китапханә, университет һәм фәнни үзәкләргә юллана.

● Фән дөньясында



Руфинә ГАБДРАХМАНОВА

# Татар ДНКсы ниләр яшерә?

**«Идел буе татарларының генетик портреты: ДНК ниләр яшерә?» монографиясенең авторы – университет галимәсе Ольга Кравцова. Ул күзгә күренмәс дөньяның серләрен чишәргә алынган. Бу тикшеренүләр антропология, тарих өчен генә түгел, медицина өлкәсе өчен дә бик әһәмиятле икән.**



КФУның биохимия һәм биотехнология кафедрасы доценты, молекуляр-генетик анализ лабораториясе җитәкчесе Ольга Кравцова Идел буе татарларының тарихи генетик портретын торгызырга хыяллана. Фәнни тикшеренүләре өчен кирәкле ДНК үрнәкләрен Урта Идел буенда табылган каберлекләрдән алырга була. Ләкин әбибабаларыбызның чәч һәм күз төсе нинди булганны белер өчен, борынгы калдыклар гына җитми икән. Моның өчен хәзерге татарларның да ДНК үзенчәлекләрен өйрәнү кирәк.

Борынгылар сере башка фән өлкәсе галимнәре тарафыннан моңа кадәр шактый чишелә килде. Антропологларның зур хезмәте белән борынгы кешеләрнең гәүдә төзелешләре, йөз-кыяфәте торгызылган булса да, татарларның борынгы бабалары җирән, кара яки сары чәчле булганлыгы һаман билгеле түгел.

– Без әлеге бушлыкны тутырырга телибез, – дип сөйли Ольга Кравцова. – 2006 елда ук борынгы ДНКны өйрәнүнең үзенчәлекле ысулын ачтык. Уздырылган тикшеренүләр кабердәге балаларның женесен, үлгәннәрнең туганлык мөнәсәбәтләрен билгеләргә мөмкинлек тудырды.

КФУда популяция тикшеренүләре якынча 2000нче еллардан бирле бара. Беренче этапларда анализ бик әкрен темпларда башкарылган, чөнки ДНК үрнәкләре базасы юк дәрәҗәсендә. Аны туплау – үзе бер авыр хезмәт. Тикшеренүләрне аппарат түгел, ә галимнәр үз куллары белән үткәргән. Әмма хәзер инде фән технологияләре алга китте. «3 көн уздырыла торган анализларга хәзер 3 сәгать тә җитә. Дисталәгән ДНК үрнәген полимераз чылбыр реакциясе (ПЦР) 15 төрле генетик маркер буенча тикшереп чыгара», – дип, лаборатория мөмкинлекләрен тасвирлый Ольга Александровна.

Молекуляр-генетик анализны ДНКның хәзерге үрнәкләрендә үткәрү күпкә җиңелрәк, шуңа күрә эшне алардан башлаячаклар. Замандашларның генотиплары турында мәгълүмат күбрәк булган саен, борынгы кеше организмының серләрен чишәргә уңайлырак булыр дип көтелә.

КФУ галимнәре, нигездә, Идел буе татарларының ДНКлары белән эшлиләр. Аларның саны 2 млн кеше тирәсе санала, ләкин генетиклар базасында Татарстан антропологлары тарафыннан җыелган 1 мең генә үрнәк бар икән.

– Бу материаллар берничә проектны берьюлы алып барырга мөмкинлек бирә, – дип аңлата Ольга Кравцова. – Мисал өчен, Новосибирскидагы коллегаларыбыз белән Идел буе татарларында очрый торган тромбофилия, бавыр күзәнәкләре бозылу, яман шеш авыруларын барлыкка китерүче мутацияләр ешлыгын тикшерергә планлаштырабыз. Ләкин мондый төр авыруларның барлыкка килүенә геннар гына түгел, тышкы факторлар – яшәү рәвеше, начар гадәтләр, экология, һава торышы да тәэсир итә.

Ольга Кравцова фикеренчә, иң зур практик файда фармакогенетикадан булырга тиеш. Әлеге фән кешеләрне индивидуаль якын килеп дәвалауны күзаллый. Мисал өчен, дарулар, аларның күләме һәм химия терапиясенең эффективлыгы һәр кеше өчен төрле булырга мөмкин. Дөрес, генетиклар тәкъдим иткән мәгълүматлар практикада кулланылсын өчен, булачак табибларга фармакогенетика курсы укытылырга тиеш. Бу курслар биохимия һәм биотехнология кафедрасында эшләнә икән инде.



## «ДНК үрнәгегезне фәнни тикшеренүләр өчен тапшырыр идегезме?» дигән сорау белән 2 млн татарның берничәсенә мөрәҗәгать иттек



✦ **Айгөл Сөнгатуллина, КФУның Яшьләр сәясәте буенча департаменты белгече:** «Моңа кадәр мондый төр тикшеренүләр турында бер дә ишеткәнем булмады. Бу бик кызыклы тикшеренү, миңа калса. Миннән файда булса, үз өлешемне бик теләп кертер идем, чөнки миңа барысы да татарга охшамаганымны әйтәләр. Ә, чынлыкта исә, минем кан – эти һәм әни ягыннан чип-чиста татар каны. Чын татарның нинди булуын үземнең дә бик беләсем килә».



✦ **Диләнур Ахунҗанова, КФУ аспиранты:** «Мин бу мәсьәләгә уңай карыйм, чөнки хәзер фән төрле яктан да үсәргә тиеш. Татарларның портретын тикшерүдә тарих, этнография, филология фәннәре белән генә чикләнеп калмыйча, хәзерге заманда аеруча актуаль булган биохимия, биофизика фәннәренең дә бу мәсьәләдә катнашуы зур һәм сыйфатлы нәтиҗәләргә китерәчәк. Проблема бер яктан гына түгел, комплексны чишелергә тиеш. Ольга Кравцованың бу өлкәдә тикшеренүләре үз нәтиҗәсен бирер, дип уйлыйм. Моңа хәзерге заман кешесе, шул исәптән мин дә, ярдәм итәргә әзер. Үзем Казахстанда яшәүче татарларны, аларның килеп чыгышларын, нинди халыклар белән аеруча тыгыз аралашып яшәүләрен, аларның бер-берсенә никадәр йогынты ясауларын өйрәнәм. Борынгы бабаларыбызның нинди булулары аеруча игътибарга лаек бу очракта. Ольга Кравцованың материаллары үз тикшеренүләремдә дә шактый күп сорауларга җавап табарга мөмкинлек бирәчәк, минемчә».



✦ **Гөлфия Шәвәлиева, Л.Н.Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты магистры:** «Иң беренче туган сорау: «Бу нинди нәтиҗәгә китерер?» Минем өчен иң мәһиме – тынычлык, халыклар дуслыгы! Тарихны өйрәнүнең яки тагын башка төр тикшеренүләрнең дөрес узмавыннан, билгеле бер кысаларга кертелеп җиткерелмәвеннән (милләтара түземлелекне күз уңында тотам) кайбер халыклар «кыерсытыла». Бу, үз чиратында, иминлекне боза. Ә бүгенге көндә бердәм булу бик тә мөһим!»



✦ **Илсөя Галиәкбәрова, Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлеге студенты:** «Татарларның ДНК үрнәкләрен тикшерү турында белгәч, бер мәлгә күңелемне курку басты. ДНК сүзе куркыттымы шунда?! Бәлки, бу анализны ничек тапшырасын белмәгәннәндер дә. Шулай да, куркуымны җиңеп, ДНК үрнәгемне тапшырыр идем. Экспериментларны бик яратам. Өстәвенә, әлеге тикшеренүнең нәтиҗәсе бик кызыклы булырга охшаган».

**Сүз уңаеннан**

Әгәр дә галимнәргә татар гены нәрсә яшергәнен белүдә ярдәм итәргә, ДНК үрнәкләре базасын тулыландырырга теләсәгез, КФУ төп бинасының көнчыгыш корпусындагы 107 нче кабинетка мөрәҗәгать итә аласыз.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.